ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2020 ел Баулы шәһәре №216

«Баулы муниципаль районында торак өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 20 мартындагы 73нче карары белән расланган кайбер административ регламентларга өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Хезмәт урыныннан наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 мартындагы 73нче карарына 2нче кушымта) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

Административ регламентка 1нче кушымтада 6нчы пунктта «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен)» сүзләрен өстәргә;

Административ регламентка пунктта 2нче кушымтада е) пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен)» сүзләрен өстәргә.

2. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 мартындагы 73нче карарына 5нче кушымта) түбәндәге өстәмәне кертергә:

Административ регламентка 3нче кушымтада 1нче пунктта «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен)» сүзләрен өстәргә.

3. «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү һәм исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламентына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 мартындагы 73нче карарына 7нче кушымта) түбәндәге өстәмәләр кертергә:

Административ регламентка 3нче кушымтада 12нче пунктта «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен)» сүзләрен өстәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров